**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 февраль № 103

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Украина территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән Украина гражданнарына өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме Украина территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән, качаклар дип танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыенып урын, йә вакытлыча яшәүгә рөхсәт алган, Татарстан Республикасы территориясендә фактта яши торган Украина гражданнарына күрсәтелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\103.doc